КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 29 декабрь г.Казань № 1304

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 12 апрель, 234 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары нигезләмәләре һәм аерым карарлары үз көчен югалткан дип тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 12 апрель, 234 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 гыйнвар, 9 нчы; 2016 ел, 15 август, 565 нче; 2016 ел, 16 сентябрь, 648 нче; 2017 ел, 21 март, 171 нче; 2017 ел, 31 май, 327 нче; 2017 ел, 18 сентябрь, 680 нче; 2017 ел, 10 октябрь, 784 нче; 2018 ел, 16 апрель, 252 нче; 2018 ел, 14 июнь, 474 нче; 2018 ел, 28 август, 723 нче; 2018 ел, 29 сентябрь, 885 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт комитеты үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда билгеләнгән эшчәнлек өлкәсендә товар базарларында конкуренцияне үстерү буенча максатлар һәм бурычлар өстенлекләрен тәэмин итә.»;

4.1 пунктта:

сигезенче – уникенче абзацлар үз көчен югалткан дип танырга;

унөченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«кунакханәләрне, тау чаңгысы трассаларын, пляжларны классификацияләүне гамәлгә ашыручы аккредитацияләнгән оешмалардан Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең туристлык өлкәсендәге органнары тарафыннан билгеләнгән тәртип һәм формалар нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә тиешле классификацияләр планлаштыру яки үткәрү турында хәбәрнамәләр кабул итә;».

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне гамәлгә ашыра торган оешмаларны аккредитацияләү буенча вәкаләтле орган турында» 2011 ел, 29 август, 726 нчы карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 6 июнь, 381 нче карарының 1 нче пункты;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне гамәлгә ашыра торган оешмаларны аккредитацияләү буенча вәкаләтле орган турында» 2011 ел, 29 август, 726 нчы карарына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 10 декабрь, 938 нче карары.

3. Бу карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин